ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның 5 марты № 199

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февралендәге 505 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә виноградчылык һәм шәраб ясау турында «Федераль законның 9 һәм 10 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 579-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февралендәге 505 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреншне кертергә:

2.9 пунктның 2.9.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле «з» абзацы белән тулыландырырга:

«з) «Россия Федерациясендә виноградчылык һәм шәраб ясау турында»2019 елның 27 декабрендәге 468-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясында каралган төзелеш шартларына туры килүен, төзелеш авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән торган җир кишәрлекләрендә, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләрендә һәм авыл хуҗалыгыннан файдалану зоналары составындагы, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләре зоналары составындагы, милек хокукында, аренда хокукында яисә башка законлы нигездә шәраб җитештерү хуҗалыкларына яисә виноградчылык хуҗалыкларына караган торак пунктлардагы җир кишәрлекләрендә, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләрендә, башкарылган очракта, раслау.».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында:https://Leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче И.Г. Шәмәрданов

Галимова Л.М.
5-44-72